**Родной язык (татарский)" по УМК "Сәлам"**
**1-4 классы**

Федераль Дәүләт стандартларында белем бирү системасы системалы-эшчәнлекле юнәлешкәкорыла һәм системаны барлыкка китерә торган төп компонент буларак нәтиҗәкүрсәтелә. Бу - предмет, метапредмет, шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр. Стандартларда күрсәтелгән бу концептуаль методологик нигез барлык фәннәрне укыту системасына да, шул исәптән рус телле балаларга татар теле һәм әдәби уку системасына да карый. Ягъни рус телле укучыларга татар теле укыту системасының барлык компонентлары: программалар, укыту-методик комплектлары, дәрес процессы, контроль, идарә итү, белем күтәрү һ.б. – барысы да бер максатка – нәтиҗәгә хезмәт итә.

Программа "Татар теле" дәресләре вакытында рус телле укучыларының татар телендә аралашу компетенцияләрен үстерүне максат итеп куя.

Тәкъдим ителә торган программа "Сәлам" укыту- методик комплекты ярдәмендә укучыларга белем бирүне планлаштыру, уку-укыту процессын тәэмин итү максатын күздә тота. Ул "Сәлам" УМКсы ярдәмендә рус телле укучыларга татар телен укыту буенча эш программасын төзү өчен нигез булып тора һәм ул укыту предметының мәҗбүри өлешен тәшкил итә. Мәктәпнең эш үзенчәлегеннән чыгып, укучыларның индивидуаль мөмкинлекләрен исәпкә алып, уку материалын өйрәнүгә сәгатьләр саны бүленеше һәм материалны өйрәнү эзлеклелеген, эчтәлекне киңәйтү, шулай ук укучыларның коммуникатив компетенциясен формалаштыру юлларын башкачарак тулыландыруны теләп, укытучылар эш программасына үзгәрешләр кертә алалар. Бу үзгәрешләр эш программаларының аңлатма язуында чагылыш табарга тиеш.

**Рустелле укучыларга татар теле укытуның төп максатлары**

Татар теленә өйрәтүнең төп максатлары: укучыларның аралашу даирәсен, аралашу ситуацияләрен исәпкә алып, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре (тыңлап аңлау, сөйләү, уку, язу) буенча укучыларда коммуникатив компетенция (аралашу осталыгы) формалаштыру; укучының танып белү, гомуми уку күнекмәләрен, сөйләм культурасын үстерү; татар милләтенә, аның тарихи һәм мәдәни хәзинәләренә карата хөрмәт тәрбияләү; укучыларны мәдәниятара диалогка тарту; татар телен дәүләт теле буларак өйрәнүгә ихтыяҗ тудыру.

Сайланылган эчтәлек укучыны рухи һәм әхлакый яктан тәрбияләү, укуның универсаль гамәлләрен формалаштыру максатларына хезмәт итә. Укыту процессы коммуникатив методның төп принципларын исәпкә алып оештырыла. Ул аралашуга аралашу аша өйрәтү принцибына корылган. УМК яңа гына мәктәпкәчә уку һәм тәрбия бирү үчреждениясен тәмамлаган балаларны уен прцессы аша телгә өйрәтү шартларын тудыра, ягъни тормышта телне куллану шартларына якынлаштыра. Бу укыту процессын укучыларның шәхси ихтыяҗларын, теләк-омтылышларын, индивидуаль-психик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештыруны тәэмин итә. Аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик-грамматик материалны укучыларның мөстәкыйль куллануын тәэмин итү үрнәк күнегүләр бирү һәм ситуацияләр тудыру аша тормышка ашырыла. УМКда телне функциональ төстә өйрәнү принцибы һәрдаим истә тотыла, ягъни лексик-грамматик материал коммуникатив максаттан, аралашу ихтыяҗыннан һәм куллану ешлыгыннан чыгып билгеләнелә. Шулай ук ана телен исәпкә алу принцибы да исәпкә алына.

Рус телле укучыларга татар теле укытуның максаты киңкырлы, һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

*Танып белү максатының эчтәлеге*

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы мәдәниятеннән тыш, шушы төбәктә яшәүче башка халыклар мәдәнияләрен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Шунлыктан укучыларга дәресләрдә бу хакта да мәгълүмат бирелә, программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын мохит белән якынлаштыруга нигезләнә.

Татар исемнәрен, топонимнарын дөрес әйтә белергә өйрәтү, укучыларны аларның семантикасы белән кызыксындыру, балалар фольклоры, татар халкы авыз иҗаты, күренекле әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру - башлангыч этапта танып белү максатының төп эчтәлеген тәшкил итә.

*Үстерү максатының эчтәлеге.*

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Балаларның психологик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә:

- логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дидуктив фикерләүне үстерү;
- хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны арттыру;
- аралаша белү сәләтен үстерү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык сәләтләрен һ.б.ны үстерү.

Программага сайланга эчтәлек нигезендә, сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча эш оештырганда, бу максат беренче планга куела.

*Тәрбияви максатның эчтәлеге.*

Укучыларның тиешле дәрәҗәдәге тәрбиялелегеннән башка укыту процессын оештыру мөмкин түгел. Тәрбия процессы укытуның эчтәлеге һәм методларына бәйле, шунлыктан программа эчтәлеген сайлаганда, материалның тәрбияви мөмкинлекләре исәпкә алына. Балаларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән, аларны кызыксындырган мораль проблемаларны үзэченә алган эчтәлек, беренчедән, укыту процессында тәрбияви функция башкарса, икенчедән, турыдан-туры коммуникатив мотивация тууга бәйле була.

Программада тел өйрәнергә теләк белдергән баланың күңелен яулардай җырлар, татар мәдәнияте, этикет нормалары белән таныштырырдай уеннар, фольклор материаллары тәкъдим ителә.

*Белем бирү максатының эчтәлеге.*

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә кулланыла алырлык дәрәҗәгә җитү зарур. Укучылар һәр өйрәнелгән материалны сөйләм процессында мөстәкыйль рәвештә гамәли кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

Эш программасы Татарстан Республикасының Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Гомуми белем бирү оешмаларында рус телендә сөйләшүче балалар өчен “Татар теле” предметыннан үрнәк программа”га (Авторлары: Р.З. Хәйдәрова, К.Ф.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова. – Казан, 2016 UPR: http://mon.tatarstan.ru/primernye_rabochie_programmy.htm) нигезләнеп төзелде.

Әлеге эш программасы “Татар теле” фәннәрен үзләштерү өчен бирелгән 99 сәгать, ә 2-4нче сыйныфлар өчен 105әр сәгать күләмен истә тотып төзелә**.** “Сәлам” УМКсы

нигезендә “Татар теле” һәм “Әдәби уку” дәресләре бәйләнештә алып барыла, һәм “Әдәби уку” дәресләрендә тәкъдим ителгән текстлар “Татар теле” дәресләрендә үзләштерелгән грамматик материалны ныгыту максатыннан кулланыла.” Сәлам” УМКсы нигезендә татар теле һәм әдәби уку дәресләре бер дәреслек нигезендә алып барыла. Еллык планлаштырылган сәгатьләрнең татар теле фәне бүленеше түбәндәгечә була:

1 сыйныф: татар теле – атнага 2 сәг (66 сәг);

2 сыйныф: татар теле – атнага 2 сәг (70 сәг);

3 сыйныф: татар теле – атнага 2 сәг (70 сәг);

4 сыйныф: татар теле – атнага 2 сәг (70 сәг).

Дәресләр “Сәлам!” УМКсы нигезендә түбәндәге уку-укыту әсбаплары һәм дәреслекләре ярдәмендә оештырыла:

Р.З.Хәйдарова, Н.Г.Галиева “Күңелле татар теле”. Дүртьеллык башлангыч рус мәктәбенең 1 нче сыйныфы өчен татар теле һәм әдәби уку дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен). Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2015

Бәхтиев Р.Ф., Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафетдинова Г.В., Маркова Э.М.,Хөснетдинова Х.Х., Якупов Р.Н. Сәлам! 1нче сыйныф: рус телендә белем бирү оешмаларының татар телен өйрәнүче укучылары өчен уку әсбабы. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2017.

Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Ахметзянова, Н.Г.Галиева “Күңелле татар теле”. Дүртъеллык башлангыч рус мәктәбенең 2 нче сыйныфы өчен татар теле һәм уку дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен).Казан,”Татармультфильм» нәшрияты,2013

Бәхтиев Р.Ф., Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафетдинова Г.В., Маркова Э.М.,Хөснетдинова Х.Х., Якупов Р.Н. Сәлам! 2нче сыйныф: рус телендә белем бирү оешмаларының татар телен өйрәнүче укучылары өчен уку әсбабы. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2018.

Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Ахметзянова, Л.А.Гиниятуллина “Күңелле татар теле”. Дүртъеллык башлангыч рус мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен татар теле һәм уку дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен).Казан,”Татармультфильм» нәшрияты,2013

Бәхтиев Р.Ф., Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафетдинова Г.В., Маркова Э.М., Хөснетдинова Х.Х., Якупов Р.Н. Сәлам! 3нче сыйныф: рус телендә белем бирү оешмаларының татар телен өйрәнүче укучылары өчен уку әсбабы. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2018.

Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Ахметзянова, Л.А.Гиниятуллина “Күңелле татар теле”. Дүртъеллык башлангыч рус мәктәбенең 4 нче сыйныфы өчен татар теле һәм уку дәреслеге (рус телендә сөйләшүче балалар өчен).Казан,”Татармультфильм» нәшрияты,2014

Бәхтиев Р.Ф., Гаппасова Р.Ч., Карпухина Н.И., Кашафетдинова Г.В., Маркова Э.М.,Хөснетдинова Х.Х., Якупов Р.Н. Сәлам! 4нче сыйныф: рус телендә белем бирү оешмаларының татар телен өйрәнүче укучылары өчен уку әсбабы. – Казан: “Мәгариф-Вакыт” нәшрияты, 2018.